**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Нурлат шәһәре Советы**

**КАРАР**

**21.03.2025 ел** **№ 139**

**Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәренең Шикәрчеләр микрорайоны стадионына В. С. Белов исемен бирү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 21 пункты, «Җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 15 өлешенең 21 пункты нигезендә РСФСРның атказанган укытучысы, Нурлат шәһәренең 3нче мәктәбенең физик культура укытучысы Виктор Степанович Белов истәлеген мәңгеләштерү максатларында «Татарстан Республикасында үзидарә турында", 2024 елның 14 ноябрендәге "Шикәрчеләр микрорайоны халкы җыенында җәмәгать тыңлаулары (ачык гавами докладлар) турында" 1нче беркетмә нигезендә, Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Нурлат муниципаль районының Нурлат шәһәрендәге Шикәрчеләр микрорайоны стадионына РСФСРның атказанган укытучысы Виктор Степанович Белов исемен бирергә һәм алга таба аны «В. С. Белов исемендәге стадион» дип атап йөртергә.
2. Әлеге карарны Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга http://nurlat.tatarstan.ru/.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Нурлат шәһәре Советының социаль өлкә, мәдәният, мәгариф, тәрбия, спорт һәм яшьләр сәясәте мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.
4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Нурлат шәһәре Советы Рәисе Д.А. Ишкинеев